РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

18.08.2023 | № 152-п

«Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Шәмәрдән авылында гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын «Биологик чистарту корылмалары төзү һәм канализация коеларын алмаштыру» объектына карата төзү һәм реконструкцияләү» линияле объект өчен территорияне планлаштыру һәм ызанлау проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставының 19 статьясы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының 2006 елның 21 ноябрендәге 94 номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районында гавами тыңлаулар турында нигезләмә нигезендә һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 14 июлендәге 1042-п номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Шәмәрдән авылында гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын «Биологик чистарту корылмалары төзү һәм канализация коеларын алмаштыру» объектына карата төзү һәм реконструкцияләү» линияле объект өчен территорияне планлаштыру һәм ызанлау проектын эшләү буенча карары нигезендә әзерләнгән линия объектын урнаштыру өчен территорияне ызанлау проекты һәм проекты буенча гавами тыңлаулар ярдәмендә фикер алышуда катнашу хокукларын үтәү максатларында

КАРАР БИРӘМ:

1. «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Шәмәрдән авылында гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын «Биологик чистарту корылмалары төзү һәм канализация коеларын алмаштыру» объектына карата төзү һәм реконструкцияләү» линияле объект өчен территорияне планлаштыру һәм ызанлау проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. Билгеләргә:

2.1. Гавами тыңлаулар уздыру вакыты - 2023 елның 18 сентябре 9:00 сәгатьтә

2.2. Үткәрү урыны - Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы,

Шәмәрдән авыл җирлеге, Шәмәрдән авылы, Яшьләр ур., 8 й., Шәмәрдән авылы мәдәният йорты бинасы.

2.3. Фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар Саба муниципаль районы, Байлар Сабасы ш.т.б., Г.Закиров урамы, 52 йорт, 105 бүлмә адресы буенча тапшырылырга мөмкин (эш көннәрендә 8:00дән-16:30га кадәр).

2.4. Чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар бирү вакыты - 2023 елның 18 сентябре.

3. Саба муниципаль районы Башкарма комитетына «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында гавами тыңлауларны оештыру һәм гавами тыңлауларны уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 20 апрелендәге 209 номерлы Саба муниципаль районы Советы карары нигезендә гавами тыңлаулар уздыруны тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетына:

– 2023 елның 18 августына кадәр әлеге карарны, территорияне планлаштыру һәм ызанлау документлары белән бергә, Саба муниципаль районының рәсми сайтында (http://saby.tatarstan.ru) «Ачык тыңлаулар» бүлегендә бастырып чыгарырга.

– «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында тиешле мәгълүмат урнаштыру һәм билгеләнгән процедураларны бастырып чыгару юлы белән гавами тыңлаулар уздыруны тәэмин итергә;

– ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы бәяләмәне «Интернет» челтәрендә -Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтының «Ачык тыңлаулар» бүлегендә бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Саба муниципаль районы Башлыгы урынбасары Р.Р. Закирҗановка йөкләргә.

Саба муниципаль
районы Башлыгы                                        Р.Н. Минниханов